БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«31» 03 2023 ел № 127

2023 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең, гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең, гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү методикасына туры китереп, «Торак урынның бер квадрат метрының уртача исәп-хисап базар бәясен куллану турында» 2023 елның 30 мартындагы 26 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. 2023 елга гаилә әгъзаларының яисә ялгыз яшәүче гражданның милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмнәрен түбәндәгечә билгеләргә:

1.1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 407700 сум;

1.1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен - 815400 сум;

1.1.3. Өч кешедән торган гаилә өчен - 1223100 сум;

1.1.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен - 1630800 сум;

1.1.5. Биш кешедән торган гаилә өчен - 2038500 сум;

1.1.6. Алты кешедән торган гаилә өчен - 2446200 сум;

1.1.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен – 2853900 сум;

1.1.8. Сигез кешедән торган гаилә өчен - 3261600 сум.

1.2. Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләме 8542,40 сум тәшкил итә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов

Балтач район башкарма комитетының
2023 елның 31. 03.
127 номерлы карарына
кушымта

**2023 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең, гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү**
**МЕТОДИКАСЫ**

1. Найм шартнамәләре буенча торак урыннары бирү нормасы буенча торак урыннары алуның базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече (алга таба - исәп-хисап күрсәткече) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

СЖ = НП х РС х РЦ,
биредә:
СЖ - исәп-хисап күрсәткече;
НП - муниципаль берәмлектә гаиләнең бер әгъзасына торак урыны бирү нормасы;
РС - гаилә әгъзалары саны;
РЦ - торак урынның әлеге муниципаль берәмлекнең уртача шартларына һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин ителешкә туры килә торган Татарстан Республикасында торак урын сатып алуга түләүсез субсидияләр исәпләү өчен тиешле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән гомуми мәйданның бер квадрат метрының уртача базар бәясеннән артмаган торак урын мәйданының бер квадрат метрының уртача исәпләнгән базар бәясе. (Балтач район башкарма комитетының 2023 елның 30 мартындагы 126 номерлы карары нигезендә 22650 сум тәшкил итә)
а) ялгыз яшәүче граждан өчен:
СЖ = 22650х 18 = 407700 сум
б) ике кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 22650 х 36 = 815400 сум
в) өч кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 22650 х 54 = 1223100 сум
г) дүрт кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 22650 х 72= 1630800 сум
д) биш кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 22650 х 90 = 2038500 сум
е) алты кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 22650х 108 =2446200 сум
ж) җиде кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 22650 х 126 = 2853900 сум
3) сигез кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 22650 х 144 = 3261600 сум.

2. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме СЖ исәп-хисап күрсәткеченә тигез дип кабул ителә.

Граждан гаиләсенең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме түбәндәгечә билгеләнә:

1) торак урын сатып алу өчен ипотека кредиты алу мөмкинлеге булган шәһәрләрдә - СЖ исәп-хисап бәясе буенча торак урын алуга агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле булган, гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем дәрәҗәсеннән чыгып, түбәндәге формула буенча билгеләнә:

**ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1 - (1 + ПС) - КП) / (0,25 х РС),**

биредә:

ПД - гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәп-хисап бәясе буенча торак урын алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме;

СЖ - исәп-хисап күрсәткече;

ПС - бер айга кредит буенча процент ставкасы (унлы вакланма), (2023 елның 28 февраленә Россия Федерациясе Үзәк Банкы ставкасы елына 7,5%, ягъни 7,5/100/12 айга = 0,00625 айга);

КП - кредитның барлык вакыты буенча кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны) (2023 елның 1 гыйнварына Россия Федерациясе Үзәк Банкы мәгълүматлары буенча 289,4 ай);

РС - гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасы белән фатир бәясенең чагыштырмасы;

0,25 - кредит буенча түләүнең гаиләнең айлык җыелма кереме белән чагыштырмасы;

**Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен исәпләү**

| НП - торак урынның нормасы (кв. м) | СЖ - торак урын сатып алуның базар бәясе (СЖ = РС х РЦ х НП) (сум) | РС - гаилә әгъзалары саны (кеше) | РЦ - торак бинаның 1 квадрат метрының базар бәясе (сум) | ПС - кредит буенча айлык процент ставкасы, % | КП - кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (ай) | Кредит суммасы белән фатир бәясенең чагыштырмасы | Кредит буенча түләүнең айлык җыелма керем белән чагыштырмасы | ПД - керемнең максималь күрсәткече (сум). (1 кешегә) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | |
| | | | 22650 | 7,5/100/12= 0,00625 | 289,4 | 0,7 | 0,25 | |
| 18 | 407700 | 1 | 22650 | 0,00625 | 289,4 | 0,7 | 0,25 | 8542,40 |
| 36 | 815400 | 2 | 22650 | 0,00625 | 289,4 | 0,7 | 0,5 | 8542,40 |
| 54 | 1223100 | 3 | 22650 | 0,00625 | 289,4 | 0,7 | 0,75 | 8542,40 |
| 72 | 1630800 | 4 | 22650 | 0,00625 | 289,4 | 0,7 | 1 | 8542,40 |
| 90 | 2038500 | 5 | 22650 | 0,00625 | 289,4 | 0,7 | 1,25 | 8542,40 |
| 108 | 2446200 | 6 | 22650 | 0,00625 | 289,4 | 0,7 | 1,5 | 8542,40 |
| 126 | 2853900 | 7 | 22650 | 0,00625 | 289,4 | 0,7 | 1,75 | 8542,40 |
| 144 | 3261600 | 8 | 22650 | 0,00625 | 289,4 | 0,7 | 2 | 8542,40 |